СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №42 (7215) | 11 апрель, 1991 ел ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

## Квартал планы үтәлде

Норлат трикотаж ательесы күрсәткечләрен айдан-айга срогыннан алда үтәп килә. Бу квартал азагында да аларның шатлыгы зур иде: планнан тыш 11 мең 800 сумлык продукция җитештерделәр. Бу уңыш коллективта унганнарның тырыш хезмәте нәтиҗәсе, әлбәттә. Бәйләүче Венера Вафиевна Тарасова—нәкъ шундыйларның берсе. Ул бу квартал нәтиҗәләре буенча сыйфат билгесе отличнигы дигән исемгә лаек булды. Шулай ук апалы-сеңелле Гөлкәй һәм Миләүшә Җәлаловалар да планны 110—120 процентка үтәүләре белән үрнәк булып торалар.

Л. КАБАНОВА.

# 12 апрель—космоска беренче кеше очуга 30 ел





Сулдагы рәсем: Мәскәү. 1961 елның 14 апреле. Мәскәү хезмәт ияләренең Кызыл мәйданда кешенең космоска дөньяда иң беренче тапкыр очышының уңышлы тәгәлләнүенә багышланган митингы.

Уңдагы рәсем: СССР-ның очучы-космонавты, Советлар Союзы Герое Юрий Алексеевич Гагарин.

ТАСС фотохроникасы.

## КАССИРЛАРНЫҢ ХӘЛЛӘРЕ МӨШКЕЛ

Хәтерегездәме 100, 50 сумлык акчалар алышынганда халык саклык банкына ничек ябырылган иде. Бу хакта искә төшерүебезнең сәбәбе шул: акчага кагылышлы сүз безне яңадан эзәрлекли башлады: 25, 10 лыкларны алмаштыралар икән дигән имеш-мимешләр таралды. Халык яңадан саклык банкын «штурм»га алды.

—4 апрель көнне башланган иде бу мәшхәр, әле бүгенге көнгә кадәр дәвам итә,—ди бу хакта борчылып, саклык банкы управляющие В.Ф.Гайсин. — Әле кайчан гына халык банктан акчаларын алырга дип ыгы-зыгы килде, хәзер киресенчә кулда булган барлык акчаларын безгә тапшыралар. Көннәр буе чиратта торалар, этешә-төртешә тәрәзәләрне ватуга кадәр барып җитteләр. Без шундый кыен хәлдә калкык. Кассирлар төнге 12 гә кадәр акча санап утыралар, филиалларны кертмичә, өчәр йөз мең сум керем саныйбыз. Шуны әйтәсе килә: безгә өстән әлегә акча алмашу турында бернинди фәрман, һичнинди хәбәр дә килмәде. Бер мәртәбә авызы пешкән халык тизрәк акчасын саклык кенәгәсенә күчерергә ашыга.

## • Колхозларда үзара тикшерү бара

# Уңай бәяләнде

Узган җомга һәм дүшәмбе көннәрендә үзара ярышучы «Заря» һәм «Россия» колхозларында техниканың язгы кыр эшләренә әзерлеген үзара тикшерү булды. Иң элек шуны билгеләргә кирәк: быелгы катлаулы шартларда хуҗалыклар әлеге эшкә бик җаваплы караганнар, техника нигездә яхшы сыйфатта әзерләнгән дип табылды. «Заря» колхозында аерата культиваторларның әзерлек дәрәҗәсе әйбәт. Ә «Россия»дә тырмалар иң югары балл белән бәяләнделәр. Бирегә чәчүгә чыгачак техника ике арен да коллективы җаваплылыгында. Комиссия беренче урынга ... тавыштан диярлек икенче —В. П. Мандрейкин звеносының әзерлегеген яхшырак дип тапты һәм ярыш шартларында күрсәтелгән 150 сум премия әлеге звеного тапшырылды.

Комиссия хуҗалыкларның чәчү чорына һәрьяклы әзерлегенә игътибар итте. Зарялылар да, россиялеләр дә быел кырда ике сменалы эш оештырырга ниятлиләр, бу уңайдан кадрлар мәсьәләсе хәл ителгән иде. Механизаторларны тукландыру турында да уйланылган, пешекчеләр беркетелгән, россиялеләр икенче блюдо гарниры өчен ярманы үзләре эшләгәннәр, яшелчә запасы да җитәрлек. Ризыкны 2 урында кырда ук пешерү күздә тотыла.

Зарялылар исә аны кырга алып чыгып таратырга уйлыйлар.

Чәчүне идеологик тәэмин итү турында да һәр ике як та уйлаган. Бу җәһәттән «Заря» колхозына тагы берничә вагончык булдырырга тәкъдим ителде. Россиялеләр дүрт вагон әзерләп, аны кирәк-яраклар белән җиһазлап куйдылар инде. Чәчүне уңышлы үткәрүдә болар һәммәсе үзенең уңай ролен уйнаячак. Ә чәчү җиңел булырга охшамый. Дөрес, «Россия» колхозында салам тулысынча җыелган, көздән сөрелми калган мәйданнар да күп түгел. «Заря»да исә соңгысы байтак исәпләнә. Шуңа да чәчүгә чыкканчы тикшерү вакытында күрсәтелгән кимчелекләрне төзәтергә, техниканы тагы бер кат күздән кичерергә кирәк дигән фикергә килделәр игенчеләр.

Ю. ТЕРЕНТЬЕВ,
«Россия» колхозы рәисе.

# Профсоюз активы укый

3 апрельдә агропромышленность комплексы работниклары профсоюзы райкомында колхоз-совхоз, агропромышленность комплексына кергән предприятие һәм оешмалар профсоюз комитетлары рәисләре катнашында профсоюз активы укуы үтте.

Авыл хуҗалыгы идарәсе юрисконсульты З. М. Мәхмүтов анда катнашучыларны колхоз уставы, хезмәт законлылыгының төп мәсьәләләре, хезмәт бәхәсләрен карауда профсоюз эшчәнлеге турында мәсьәләләр белән таныштырды.

Торак турында законның төп мәсьәләләре турында АПК профсоюзы райкомы каршындагы штаттан тыш юридик консультация мөдире И. Г. Гыйләҗев сөйләде.

Пенсия һәм пособиеләр алучыларга компенсация түләү тәртибен район социаль-тәэминат бүлегенең баш бухгалтеры А. П. Медянцева аңлатты һәм ул күпсанлы сорауларга җавап бирде.

АПК работниклары профсоюзы райкомының баш бухгалтеры В. П. Алексеева соңгы вакытта хатын-кызлар, гаилә хәлен, аналарны һәм балалыкны саклау буенча хөкүмәтебез тарафыннан кабул ителгән яңа чаралар белән таныштырды.

АПК работниклары профсоюзы райкомы рәисе Г.К. Пакшин чыгышы 1991 елда язгы кыр эшләрен оештыру һәм үткәрүдә профсоюз комитетларының ролен яктыртуга багышланган иде.

Е. ШАШОРИНА.

## КАЙДА НӘРСӘ НИЧЕК

СССР Дәүләт банкы рәисе В. Геращенко интервьюсында әйтелгәнчә, тора-бара бездә зур кәгазь акчалар—200, 500 һәм 1000 сумлыклар чыгарылачак. Югыйсә, вак кәгазь акчаларны чиктән тыш күп сугарга туры килә. 200 сумлыклары әйләнешкә быел ук кертелергә тиеш. Хәер, бу бәяләрнең артуын ни дәрәҗәдә тоткарлап тора алуыбызга һәм керемнәрнең җитештерү нәтиҗәлелегенә ни дәрәҗәдә тәңгәл килүенә бәйле булачак.

Укучыларыбыз: «Товар сатуга 5 процентлы налог яңа күтәренке бәяләргә кертелгәнме?—дип сорыйлар. СССР Бәяләр буенча дәүләт комитетында әйтүләренчә, бу налог дәүләтнең яңа ваклап сату бәяләренә кертелмәгән.

x x x

1983 елда совет истребителе бәреп төшергән Көньяк Корея самолеты пассажирларының кардәшләренә Сахалин утравына килергә рөхсәт ителәчәк. Алар монда килеп һәлак булганнарны искә алачаклар.

x x x

СССР Президенты М. С. Горбачев Польша премьер-министры Ян Кшиштоф Белецкий белән очрашты. Танышу нәтиҗәле булды. М. С. Горбачев безнең мөнәсәбәтләр «Без сезгә, сез безгә кирәк» дигән формула нигезендә корылырга тиеш диде.

x x x

5 апрельдә СССР Президенты М. С. Горбачев Румыния җитәкчесе И. Илиеску белән очрашты. Президентлар хезмәттәшлек, яхшы күршелек һәм дуслык турында килешүгә кул куйды.

x x x

Шул ук көнне РСФСР Югары Советы Рәисе Б. Н. Ельцин да Румыния Президенты И. Илиеску белән очрашты.

# Җиргә хуҗа бер: Совет

*Безнең интервью*

**Район Советының чираттагы сессиясе җир реформасы буенча район комитетын раслады. Газета корреспонденты Р. АЙЗАТУЛЛИН комитет рәисе Р. Х. ХӘСӘНОВ белән очрашты, бу органның структурасы, функцияләренә кагылышлы сорауларга җавап бирүен үтенде.**

**КОРР. Рифкат Хатыйпович, комитет һәм аның эшчәнлегенә аңлатма биреп үтсәгез иде.**

**Р.Х. Х.** Безнең комитетның штат буенча 5 кешедән торуы күздә тотыла. Ул халык депутатларының район Советы каршында оештырыла һәм, аңлашыла ки, аның алдында җавап бирә.

Функцияләргә килгәндә исә алар исеменнән үк аңлашыла. Комитет этаплап җир реформасын гамәлгә ашыра. Бер үк вакытта дәүләт җир кадастрын алып бара, аннан файдалану һәм аны саклау буенча контроль функциясен дә башкара.

**КОРР. Хәзер җир, аны алу, мөстәкыйль крестьян хуҗалыгы төзүгә кагылышлы сораулар авыл һәм шәһәр кешеләрен дә кызыксындыра.**

**Р. Х. Х.** Аңладым, җир алу тәртибе ничек димәкче буласыз инде. Иң алдан шуны билгеләп үтик, җирнең кем файдалануында булуга карамастан, хуҗасы бер—Совет була һәм мәсьәләне бары ул хәл итә. Аңлаешлы булсын өчен конкрет мисал өстендә карап үтик.

Җир алырга теләгән кеше Совет исеменә гариза язып бирә. Совет каршындагы депутат комиссиясе мәсьәләне тикшерә, өйрәнә һәм Советка тәкъдим кертә. Авыл Советының җир бирү турындагы карарын район Советы раслый.

**КОРР. Гафу итегез, бу циклда сезнең комитетның катнашы юкмыни?**

**Р. Х. Х.** Бар. Авыл Советына кергән гариза нигезендә җир, аның сыйфатын, кадастрын, күләмен урында тикшерә, ачыклык кертә, чикләрен билгели. Район Советы аның тәкъдимнәренә таянып карар чыгара.

**КОРР. Җир теләсә кемгә биреләме?**

**Р. Х. Х.** Колхоз членнарына, әгәр алар крестьян хуҗалыгы алып бару өчен җир сорап гариза язсалар, колхоз яисә совхоз членлыгыннан чыгу шарт. Ул чагында җир берниндн тоткарлыксыз бирелергә тиеш. Тик бер моментны истән чыгарырга ярамый. Мәсәлән, авылда яшәүче кеше санына уртача 10 гектар җир туры килгән икән, халык ихтыяҗын, соравын искә алып, Совет җир күләмен чикләргә хокуклы. Шушы урында яшәмәүче, торак урынына теркәлмәгән кешеләр үтенече кире кагылырга, җир бирелмәскә мөмкин.

Җир бүлгәндә аның кадастры Совет (колхоз) карамагындагы җирнекеннән түбән була алмый. Җир крестьянга үз ризалыгы белән вакытлы файдалануга (срогы 3 елгача), озак вакытка (10 елгача) һәм аннан да артык вакытка, ягъни даими файдалануга бирелергә мөмкин. Аны гаилә членнарының берсенә мирас итәргә ярый, ләкин бүлгәләүгә юл куелмый. Бу җирдән файдалануның бер төре. Моннан тыш ул файдалануга һәм арендага бирелергә мөмкин.

Җирдән файдалануга булган таләпләр үтәлмәгәндә ул кире кайтарып алынырга да мөмкин.

**КОРР. Җир бүленмәгән очракта сораучы ни эшли ала?**

**Р Х Х.** Мәсьәлә үтенеч биргәннән соң 2 ай эчендә каралырга тиеш. Карар белән килешмәгән кешеләр судка мөрәҗәгать итә алалар.

**КОРР. Районда җир алырга теләүчеләр байтакмы соң?**

**Р. Х. Х.** Әлегә бездә җир алган аерым крестьян хуҗалыклары юк. Бездә эчке хуҗалык исәбе һәм килешү нигезендә эшләүче аренда коллективлары күпчелек. Алар колхоз белән бәйләнештә сатып алу-сату принцибында продукция җитештерәләр һәм реализациялиләр.

**КОРР. Мәскәү өлкәсендә шәһәр халкына дача участоклары быел күпләп бирелә.**

**Р. Х. Х.** Андый алым бездә дә кулланыла. Үткән елларда 2965 гаиләгә 146 гектардан артык җир участогы бүлеп бирелде. Шәһәр предприятиеләре хуҗалыклардан 200 гектар чамасы җир алып ел саен бәрәнге һәм башка культуралар чәчәләр.

Быел РСУга тагын 7 гектар җир бүленде.

**КОРР. Теләүчеләргә җир бүлүнең тагын нинди формалары кулланыла?**

**Р. Х. Х.** НГДУ ярдәмче хуҗалык өчен җир алган иде инде. Хәзер МСО һәм НУРБ коллективлары да берничәшәр йөз гектар алдылар. Анда хуҗалык итеп җитештергән продукцияләрен үзләрендә файдаланалар.

Шәһәр халкына индивидуаль торак төзү өчен 0,04—0,08 гектарга кадәр җир бирү күздә тотыла. Шикәр заводы һәм МСО коллективлары бу максатларга 5 әр гектар җир алдылар.

**КОРР. Авылдагы буш йортларны сатып алып, аның участогында килешү нигезендә авыл хуҗалыгы продуктлары үстерүчеләр байтак иде.**

**Р. Х. Х.** Алар 23 хуҗалык исәпләнә. 4,19 гектар җир бу хуҗалар карамагында. Авылдан йорт сатып алучыларга киләчәктә 0,3 гектарга кадәр участоктан файдаланырга рөхсәт ителә. Участок мирас булып калганда 1 гектарга кадәр җитәргә мөмкин. Шәһәр халкы үзен-үзе яшелчә һәм башка төр авыл хуҗалыгы продуктлары белән никадәр тулырак тәэмин итсә, шулкадәр яхшы ич.

Соңгы сүз итеп шуны әйтәсем килә. Татарстанда җир һәм аннан файдалану турында закон кабул ителмәгән әле. Ул мәсьәлә ТССР Югары Советының 16 апрельдә ачылачак сессиясендә хәл ителәчәк. Шуңа күрә җиргә кагылышлы проблемалар турында китерелгән мисалларда, положениеләрдә үзгәрешләр булуы да ихтимал. Була калса, газета укучыларга өстәмә рәвештә хәбәр итәрбез.



**Әкълимә Миндубаева исеме районда күпләргә таныштыр, мөгаен. Чөнки ул 4 меңчеләр рәтенә беренчеләрдән булып баскан савымчы. Узган елгы күрсәткече генә дә моны ачык сөйли. Аның еллык савымы 1990 елда да һәр сыерга 4233 килограмм тәшкил итте.**

**Алдынгы савучы 1991 елны да әйбәт кенә башлап җибәрде. Быелның өч аенда үз карамагындагы һәр малдан 771 килограмм сөт сауган ул. Хәзер дә сыерлардан көнлек савым 9 килограммнан кимеми. Ә колхоз буенча бу күрсәткеч уртача 8,8 килограмм тәшкил итә.**

Рәсемдә: «Татарстан» колхозының алдынгы савучысы Ә. Миндубаева.

**Н. Азизов фотосы.**

### КҮРҮЧЕЛӘР ЮКМЫ?

**23 мартта түгәрәк йөзле, урта буйлы, 25 яшьләрдәге Ринат Шәүкәтович Төхфәтуллин югалды. Башында кара бүрек, фуфайка, аягында кызыл эчле резина галош. Күрү, яисә аның турында белүчеләр булса, Колбай Мораса авылына Төхфәтуллиннар гаиләсенә хәбәр итүегезне сорыйбыз.**

*«Эстрада-91»*

# Конкурстан соң

«Эстрада-91» конкурсының икенче этабы да артта калды. Беренче этапта вокаль-инструменталь ансамбльләр үзара ярышкан булсалар, бу юлы тик җырчылар гына катнашты.

Һәр конкурсның үзенчәлеге, уңай яклары һәм җитешсезлекләре булган кебек, бу конкурс та алардан читтә калмады. Тик ни генә булса да аның төп максаты—яңа, яшь талантлар белән таныштыру иде. Быелгы «Эстрада-91» күпмедер дәрәҗәдәр шул хезмәтен үтәде диярга була.

Татар җырын, моңын тыңлаучының күңеленә җиткерүчеләр бар иде биредә. Яңа Итлайдан Наилә Мусина, Бикүледән Бибинур Әбделвәлиева тамашачы күңеленә хуш килерлек җырлар башкардылар.

Конкурста сәхнәгә курκып, кыюсыз гына чыгучылар белән бергә районда үткәрелгән концертларда катнашып, остарып беткән җырчылар бар иде. Әлбәттә, икенчеләренең тавышлары да көррәк чыга, үз-үзләрен тотышлары да килешле. Әйтик, район культура йорты методисты Рәсимә Шакированың табигать биргән моңлы тавышы өстенә, җырны җанытәне белән тоеп башкаруы, стабиль репетицияләр үзен сәхнәдә батыр тотарга мөмкинлек бирә, шуңа күрә ул тавышы белән дә үзе теләгәнчә идарә итә. Рәсимә «Кара миләш» җырын нәкъ шулай башкарды да. Культура йорты аккомпаниаторы Сабит Миннеханов, Колбай Мораса авылы культура йорты директоры Рафаэль Сафин һәм бию мәйданнарында җырлап шомарган Норлат егете Игорь Давыдовның да сәхнәдә үз-үзен тотышлары турында шуларны ук әйтергә булыр иде. Шунда ук сәхнәгә курка-курка, йомшак адымнар белән чыгучы, шуңа да булган тавышыннан да файдалана алмаучы кызлар да җырлыйлар иде. Билгеле, моңа һич тә алар гаепле түгел: өйрәтүче юк, репетициясез диярлек район культура йорты сәхнәсенә чыгып басу каушатмыйча калмас. Шуңа күрә алда исемнәре әйтелгән җырчылар белән соңгыларын чагыштырып бәяләү берникадәр гадел дә түгел кебек. Шуңа карамастан, жюри озак киңәшләшкәннән соң җиңүчеләрне билгели алды. Дөрес, беренче урынны бирү турында бераз бәхәс булды. Бу урынга ике җырчы—Рәсимә һәм Рафаэль дәгъва итә иде. Әмма бәхәс бик кинәт тукталды. Рәсимә үз-үзенә каршы торган булып чыкты: конкурста икешәр җыр башкарылырга тиеш булса, ул берне генә җырлады. Берниндн кыланусыз, авыл культура йортыннан килгән Рафаэль Сафин «Эстрада-91» конкурсында җиңеп чыкты. Рафаэль «Гел яшисе килә» җырын гармунга, «Тизрәк әйләнеп кайтыгыз» җырын синтезаторга кушылып башкарды. Күренеп тора, ул бу номерлар өстендә шактый эшләгән, хәрәкәтләр килешле, тавышы көр, бу урынга һичшиксез лаеклы дип табылды. Икенче урынга бер бәхәссез Рәсимә Шакирова, өченчегә Игорь Яковлев чыкты. Ул үзенең ике җырын башкарды. Җырлау рәвешен җырның табигатенә туры китереп, Игорь тамашачыларны үзенә җәлеп итеп торды. Игорь Давыдовның җырлау рәвеше рок кумирларына ошатып башкарылган булса (хәер җырлар кумирларныкы булгангадыр инде, мәсәлән, «Мальчик Евграф»—Б. Гребенщиков), Яковлевта беркемгә ошатырга тырышу юк иде.

Тамашачыларның күңелен аеруча биләгән Норлат егете Андрей Нестеров «Тамашачылар мәхәббәте» призына лаек булды. Бу очракта әйтеп үтәргә кирәк: Андрей да үзе язган җырларны башкарды, әмма җырлау манерасы бардларныкына тартым. Шундый жанрдагы җырлар конкурсында катнашса, ул һичшиксез югарырак урын алыр иде.

Җиңүчеләргә ВЛКСМ райкомы, район культура йорты белән берлектә бүләкләр, Мактау грамоталары һәм барлык катнашучыларга да истәлекле бүләкләр тапшырды.

Конкурсның кайбер җитешсез якларына да тукталасы килә. Конкурста барлыгы 13 җырчы катнашты. Район күләмендә шул хәтле генә җырчы булуына һич тә ышанасы килми. Катнашучылар да татар авылларыннан гына иде, 13 нең 10 сы татарча, өчесе русча башкаручылар булды. Ә бит конкурсның максаты ярыштыру гына түгел, күп санлы катнашучылар арасыннан яңа, яшь талантларны ачу, аларны дөньяга чыгару. Алда санаган җитешсезлекләр районда җыр сәнгатенең түбәнлеге, торгынлыкта калуы турыда сөйли дә. Бу хакта жюри члены, Норлатның беренче мәктәбендә музыка укытучысы С. С. Ефремова менә нәрсә ди:

—Җыр сәнгатенең шундый хәлгә дучар булуы, кызганычка каршы, бер бездә генә күзәтелми. Телевизор, магнитофон тавышы астында җырга сәләтне югалтуыбызны сизми дә калдык. Балаларда кечкенәдән үк җырлау сәләтен юкка чыгарабыз, үстермибез, булганны камилләштермибез. Ә менә бию, хәрәкәтләнүгә сәләт, киресенчә, камилләшә бара.

Һичшиксез, биюнең үз урыны бар, ә җырның—үзенеке. Аннары «Җырсыз кеше, канатсыз кош»,—ди бит халык.

**Ф. ГАЛИМОВА.**

# Җаваплы көннәр җитә

Язгы чәчүгә санаулы көннәр калып бара. Игенче үзенең «йолдыз» сәгатен көтә, бу җаваплы чорны мөмкин кадәр уңышлы башкарып чыгу өчен соңгы хәстәрлекләрен күрә. Әйе, быел игенчедән аерата тырышлык сорала. Елы шундый аның. Узган 1990 ел авыр, катлаулы килде. Кыр эшләренең байтагы ахырынача башкарылмады, язга калды. Әйтик, урыпҗыюдан соң 14858 гектар җир сөрелмичә калды. «Яшь көч» колхозында ул сөрү җирләренең 67 процентын тәшкил итә. «Комбайн» колхозы, «1 Май», «Правда», Синдряков исемендәге «Заря», «Алга» колхозларында, «Сөлчә» совхозында сөрелмичә калган участоклар 23—31 процент чамасы исәпләнәләр. Бу участокларны язын ике тапкыр эшкәртергә туры киләчәк,нәтиҗәдә эш күләме дә икеләтә арта.

Башкарылмый калган эшләр тагы бар. Бөртекләләрне җыйганнан соң 1724 гектар җир саламнан чистартылмады.«Алга» колхозында ул 510 гектар, «Комбайн»да 420, «Восход»та 320, «Путь к коммунизму»да 200, «Төрнәс» совхозында 150 һәм Синдряков исемендәге колхозда 124 гектар мәйданны алып тора. Бу да туфракны сөрү алдыннан әзерләү эшенә байтак тоткарлык ясаячак. Үткән елда кукуруз җыю шулай ук бик кыен шартларда барды. Шуңа аерым хуҗалыкларда бу участокларны каткат эшкәртергә туры киләчәк. Бу исә үз чиратында дымны югалту куркынычын тудыра. Сөрелгән җирләрнең сыйфаты да канәгатьләнерлек түгел. Борылыш полосалары начар, өзекләр күп—болар янә өстәмә вакыт сорыйлар.

Быелгы чәчү өчен орлык әзерләү эше дә начар һава шартларында барды. Бу, әлбәттә, орлыкның сыйфатында шулай ук чагылмый калмый.

Быел районда чәчеләсе орлыкның 1 апрельгә торышы түбәндәгечә:I класслы орлык—40,8 процент, II класслы—27,7 процент, III класслы орлык—18,1 процент һәм 13,4 процент орлык—кондициясез. Чисталык буенча 4,9 процент һәм шытым буенча 9,9 процент тәшкил итә.

Шушындый шартларда эшне уңышлы оештыру өчен өстәмә көч, аерата җаваплылык сорала. Эш күләменең артуы шулай ук техника әзерләүгә дә җитди карауны таләп итә.Башка елларда яссы кискечләр кулланылмаса, быел безгә БДТ-7, БДТ-3, БИК-3, КПШ-9, ОПТ-3-5, КПГ-2-150 кебек җайланмаларны да көйләргә, эшкә җигәргә туры киләчәк. Әмма дөресен әйтергә кирәк, бүгенге мәгълүматлардан күренгәнчә, хуҗалыкларда техниканың әзерлек дәрәҗәсе югары диеп булмый әле. Тракторларны көйләү аерата кыен хәлдә тора. Моңа, әлбәттә, ил күләмендә килеп туган запас частьләр кытлыгы да сәбәпче. Әмма ни генә булмасын, чәчү кампаниясен башкарырга һәм аны мөмкин кадәр оптималь срокларда, яхшы сыйфатлы итеп башкарырга кирәк. Шуңа да быел район оешмалары, предприятиеләрнең эшдекле ярдәменә дә исәп тотабыз. Бу җәһәттән аларның һәрберсе үз мөмкинлекләрен барлап, ярдәмгә киләсе көчләрен билгеләде инде. Хуҗалыкларда да кадрлар беркетү эшләре төгәлләнеп килә. Быел колхоз-совхозлар нигездә 2 сменада эш оештырырга уйлыйлар, ә аерым хуҗалыклар яктылык көне буена эшләргә ниятлиләр. Ни генә булмасын, иң мөһиме —һәр сәгатьне, һәр минутны рациональ куллану кирәклеген истән чыгарырга ярамый. Ә ел үзенчәлекләре белән бәйле күрсәтмәләр район җитәкчеләре, белгечләренә җиткерелде инде. Бу җәһәттән «Комбайн» колхозында ел үзенчәлекләреннән чыгып туфрак эшкәртү юнәлешендә семинар булды.Шунда ук үткән икенче семинарда баш агрономнар һәм инженерлар туфрак эшкәртү техникасының 3 варианты белән таныштылар. Мичурин исемендәге колхозда сабан һәм уҗым бодаен инкрустацияләү буенча ике тапкыр семинар үткәрелде, гамәлдәге орлык белән эшләү үзенчәлекләренә басым ясалды. Чәчүгә әзерлекнең торышы, көн бурычлары турында район күләмендә киңәшмәләр дә әледән-әле булып тора. Болар һәммәсе җаваплы кампания алдыннан игенчеләр кәефенә уңай йогынты ясарга, көн бурычларын конкретлаштырырга булыша, әлбәттә. Шулай да, төгәлрәк итеп әйтсәк, бүген игенчеләр алдында торган төп бурычлар нидән гыйбарәт соң?

Иң элек, чәчү алдыннан игенчеләргә ел үзенчәлекләренә бәйләп, алда торган эшләрнең күләмен аңлату, һәрбер механизатор алдына конкрет бурыч куеп, аны мораль-психологик әзерләү зарур. Чөнки кеше факторы һәрбер эштәге кебек үк, биредә дә төп рольне уйный. Икенчедән, кырларны тиешле тәртипкә китерү—салам калдыкларыннан чистарту, баганаларны агарту һәм башкаларны башкару кирәк. Аннан инде конкрет эшләр башлана. Уҗым культураларының күпмесе орлыкка, күпмесе яшел массага китәчәк? Күпме яңабаштан һәм өстәп чәчү үткәрергә?— боларны ачыклап, массакүләм чәчүгә кадәр башкарырга кирәк. Әзерлеге ягыннан иң әйбәт җирләргә иртә сабан культураларын, техник һәм вак орлыклы культураларны чәчү зарур. Инде начаррак эшкәртелгән җирләрне соңгы культуралар һәм сидератларга бүлү, күздән бөтенләй сөрелмәгән мәйданнарны чиста парга калдырырга тырышу зарур. Чәчү вакытында рәтләргә, азык культуралары мәйданын культивацияләгәндә минераль ашламалар кертергә (соңгысына сыекны) тырышырга кирәк. Күздән эшкәртелмичә калган участокларны сөрүгә максимум техниканы тартып, эшне группа ысулы белән, оператив оештыру зарур. Бер әйләнештә ике операцияне башкару — яссы кискечләр артыннан, дым югалмасын өчен, тырмалау үткәрүнең өстенлеген дә истән чыгарырга ярамый. Мондый эшләрне төнлә башкарырга, ә көндез чәчү эшләрен үткәрергә кирәк. Чәчү вакытында технологик операцияләр— культивацияләү һәм чәчү, чәчү һәм катоклау һәм башкалар арасында өзекләргә юл куймаска кирәклеген дә онытмагыз. Хуҗалыкларда үсемлекләр шытканчы һәм шыткач тырмалау өчен агрегатлар булдыру—бу эшкә киң алымлы СГ-21 агрегатын файдалану отышлы.

Колхоз - совхозларда үсемлекләрне корткычлардан, авырулар һәм чүпчардан саклау өчен отрядлар оештыру кирәклеген дә истән чыгарырга ярамый. Аларга алдан ук эш тәртибен аңлатып, тиешле күләмдә агу-химикатлар белән тәэмин итеп кую шарт. Чәчү— игенче өчен иң җаваплы, иң киеренке чорларның берсе. Биредә техниканы югары җитештерүчән файдалану, техник хезмәт күрсәтү звенолары булдыру, ашаузчүне урында оештыру һәм башкалар—һәммәсе төп ахыр максатка—чәчүне оптималь срокларда яхшы сыйфатлы итеп башкаруга хезмәт итә.

Шуңа да әлеге киеренке кампаниягә һәрьяклы әзерлек белән килеп, аны уңышлы үткәрү өчен игенче бөтен тырышлыгын тупласын иде.

**Н. МУСИН,**
авыл хуҗалыгы идарәсенең баш агрономы.



**Алар гаиләләре белән техникага гашыйк кешеләр. Әтиләре—Якуб абзый тегермәнче булып эшләде. Юныс менә 12 ел инде тракторда. Энеләре Җәмил белән Фәнил тимерче һөнәрен сайладылар. Юныс тракторда эшләү дәверендә техникага сак карашлы булуы белән танылды. Шуңа күрә үткән ел кайткан яңа тракторны да аңа ышанып тапшырдылар. Яз, көз айларында сөрүдә эшли, ә кышын тракторын бульдозер итеп көйли. Чөгендер алган вакытта КС-6 маркалы комбайн белән чөгендер басуына да чыкты. Техниканың кайсына гына утырса да белеп, яратып эшли. Ә хезмәт яратучы хөрмәткә дә ия, шуңа күрә иптәшләре арасында мактаулы да Юныс Фәсхетдинов.**

**Рәсемдә: «Чирмешән» колхозы механизаторы Ю. Фәсхетдинов.**

## „ШӘВӘЛИ ХИКМӘТЛӘРЕ"

26—27 март көнне пионерлар йортында бәйрәм рухы хөкем сөрде. Бу көннәрдә биредә район мәктәпләрендәге пионер активының укуы булды. Форумга мәктәп активистлары һәм өлкән пионервожатыйлар җыелды.

Биредә катнашучы йөз укучыга кечкенә актлар залы кысан булуга карамастан, пионер эшендәге хәлиткеч мәсьәләләр аларны тиз арада хәл итәргә чакыралар иде. Иң мөһим мәсьәлә—Татарстан варис-пионерлары берләгенең яңа уены «Шәвәли хикмәтләре»нә старт бирү.

Шәвәли ул әдәби образ, аның «әтисе»—Татарстанның танылган шагыйре Шәүкәт Галиев. Шәвәли —ул иң популяр автор, аның мәкаләләре газеталарда һәрдаим нәшер ителеп тора. Балалар аның «Шәвәли хатлар укый» рубрикасындагы чыгышларын, кызыклы кешеләр белән әңгәмәләрен түземсезлек белән көтеп алалар. Төрле елларда күп төрле мәшһүр рәссамнар, атказанган сәнгать эшлеклеләре Шәвәли образын иҗат итү өстендә эшләделәр.

Шәвәли балаларга сәяхәт итү һәм спорт күнекмәләре алуда авыр сикәлтәле юлларны үтәргә, беренче медицина ярдәме күрсәтүдә булышлык итә.

Безнең укуда катнашучылар да «Таныш булыйк» уенында үткен акыл буенча ярыштылар. Ярышта командаларга үзләре белән таныштырырга һәм Шәвәлине төрле хәлләрдә гәүдәләндерергә кирәк иде. Мәсәлән, «Шәвәли—кеше яшәми торган утрауда Робинзон», «Шәвәли безнең мәктәпкә килгән...»

Төшке аштан соң пионерлар җыелышлары турында фикер алыштылар, пионер һәм турист җырларын өйрәнделәр.

Икенче көнне РСЮТ методистлары һәм өченче мәктәпнең география укытучысы А. И. Абрамов укучыларны походта кирәкле турист күнекмәләренә өйрәттеләр. Аннары теорияне практика-спорт эстафетасы белән алыштырдылар. Әмма район пионерлар йортының җиһазландырылган спорт залы булмау сәбәпле, эстафетада барлык укучылар да катнаша алмадылар.

Укуда катнашучылар «Шәвәли хикмәтләре» уенын кустларда үткәрергә, анда җиңүчеләрне май аенда районда үткәреләчәк ярышларга җибәрергә карар кылып таралыштылар. Ә район ярышларында җиңүчеләр «Робинзон-91» республика палаткалы лагеренда кунак булачаклар.

**Г. МАҢЯПОВА,**
пионерлар йорты методисты.

**ӘЙДӘ КИТТЕК БАЗАРГА**



**Сауд бедуины базарга үзенең товары—дөяне әнә шулай алып барырга исәпләгән. «Нью-Йорк Таймс» газетасы язганча, җирле сәүдәгәрләр мондый «дала корабле»нең, 10.000 доллар бәя торуын әйткәннәр.**

# Түбән Норлатта—Нәүрүз

Һәр бәйрәмне матур итеп, истәлекле итеп уздыру өчен «Кондырча» колхозы җитәкчеләре зур көч куялар. Әнә шуңа Түбән Норлат авылында Нәүрүз бәйрәме дә гөрләп узды. Бәйрәмне китапханә мөдире Зәмзәмия Тимербулатова алып барды. Биредә авыл кызлары солдат хезмәтен үтәп, туган җирләренә кайткан солдатларны ипитоз белән каршы алды. Колхоз рәисе С. Ильмухин аларны котлап, кыйммәтле бүләкләр тапшырды, яңа өйләнешкән яшь парларга да бәхет теләде.Болар барысы да бәйрәмне тагын да ямьләндереп җибәрде. Тамаша залында өстәлләрдә авылның уңган киленнәре бәйрәм өчен төрледән төрле, тәмле-томлы ризыклар әзерләп килгәннәр. Рәхим итеп кайнар чәй эч, ризыклардан: нәүрүз боткасы, бәлеше, коймагы, чәкчәгеннән авыз ит!

Сәхнәдә авыл мәктәбе укучыларының Нәүрүз күренешләрен тасвирлаулары һәркемнең күңеленә хуш килде. Авыл оркестрына кушылып Норлат шәһәрендә яшәүче Зөбәрҗәт Бакирова халкыбызның моңлы һәм шаян җырларын җырлап Нәүрүз концертын башлап җибәрде, ә аннан соң авыл кызлары Лилия Сафина, Венера Куляева, Сиринә Хәммәтовалар үзләренең моңлы тавышлары белән күңелләрне дулкынландырды. Район эчке эшләр бүлеге хезмәткәре Марат Тямаев авылдашларын бәйрәм белән котлап «Норлатыма» дигән җырын башкарганда, бу моң нечкә кылларга кагылып үтеп, тамашачыларны туган як турында уйларга мәҗбүр итте, шуның белән һәркемдә горурлык хисе уятты.

Кыскасы, Нәүрүз бәйрәме әле авылда беренче тапкыр гына уздырылуына карамастан, оешкан төстә, күңелле үтте. Бу бәйрәм игенчеләребезгә язгы чәчүне уңышлы башкарып чыгар өчен яңа көч өстәр, киләсе языбыз һәркемгә бәхет алып килер дип ышанабыз.

**Т. АЛЯКИМОВА,**
Түбән Норлат авылы.

